МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.11.2022 № 551-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 26 февралендәге 87-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршлыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 26 февралендәге 87-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршлыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә (2018 елның 19 мартындагы 146-осн номерлы боерык нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) үзгәреш кертеп, 3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы икенче абзацта күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яки әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән белдерүне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмәне әзерләгәндә Министрлыкның коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы булган вазыйфаи заты мөрәҗәгатьне яки белдерүне тапшырган дәүләт граждан хезмәткәре белән әңгәмә үткәрергә, аннан язмача аңлатмалар алырга хокуклы. Мәгълүмат алу өчен Министрлык тарафыннан дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм мәнфәгатьле оешмаларга гарызнамәләр җибәрелә ала, гарызнамәләр җибәрүне дә кертеп, коррупциягә каршы тору өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасы кулланылырга мөмкин. Мөрәҗәгать яисә белдерү, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки белдерү килгән көннән соң җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Гарызнамәләр җибәрелгән очракта мөрәҗәгать яисә белдерү, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки белдерү килгән көннән соң 45 көн эчендә тапшырыла. Әлеге чор Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артыгракка түгел.».

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (В.В.Мәнихова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Р.Ә. Кузюров